Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Чәчәкле авыл җирлеге Советы

КАРАР

25.05.2022 ел № 70

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының 2016 елның 30нчы апрелендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, ТР Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 нчы апрелендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 8 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә һәр алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) буенча, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, хисап чорына, алар хисабына бу алыш-бирешләр башкарылган.»

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми порталында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чәчәкле авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Фәисханов